СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НОРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

26 декабрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№145(8157)

Бәясе билгеләнгәнчә

## Призыв тәмамланды

Декабрьнең 24ендә хәрби комиссариат быелгы сезондагы соңгы призывникларын озатты. Көзге чорда барлыгы 100гә якын егет армиягә китте. Алдан билгеләнгәнчә, алар Благовещенск, Самара, Казан, Мәскәү, Новгород, Биробиджан шәһәрләрендә, Волгоград өлкәсендә хезмәт итәчәкләр.

## Яңа елдан яңа өйгә

РИТЭК - Россия инновацион - ягулык компаниясенең Норлаттагы «ТатРИТЭКнефть» НГДУсы эшчәнлегенә ике ел була. Предприятие нефть ятмаларын үзләштерә, кара алтынны җир өстенә чыгаруны көннән-көн арттыра.

Бүген РИТЭК төп эшенә өстәп идарә бинасы - контора төзү белән дә мәшгуль. Әлегә Норлат геофизикасында урнашкан НГДУ яңа - 1998нче елда өй туе үткәрергә ниятли.

## Башкаручыдан - приставка

Октябрь (Норлат) районы суд башкаручылары киләсе елдан яңа, югарырак статус буенча - суд приставлары булып эшли башлаячак.

Үткән атнада алар Яр Чаллы шәһәренә аттестация үтәргә бардылар. Аттестация комиссиясе аларның вазифаларына туры килерлек белемнәрен канәгатьләнерлек дип тапты. Хәзер соңгы сүзне, башкаручыларны пристав итү турындагы карарны ТРның баш суд приставыннан көтәләр.





Авылда трактор аттан соң иң ышанычлы транспорт чарасыдыр,мөгаен.Үзәк юллар салына башласа да,анда әле пычраклык,машина җиңә алмаслык сазлыклар җитәрлек.Фәнис Нуруллин шундый тракторларның берсе МТЗ-80 дә эшли.Армия хезмәтеннән кайтып «Игенче» КХАсында 10 елга якын эшләү дәверендә үзен булдыклы,тырыш механизатор итеп күрсәтте.Һәрнәрсәне зур җаваплылык белән башкарырга омтыла.

Фотохәбәрчебез НАИЛ АЗИЗОВ аны көз көне комбайн астыннан чөгендер ташыган вакытта рәсемгә төшереп алган.

## Газлы йортлар саны ишәер

Районны газлаштыру программасы кысаларында башкарыла торган эшләрнең күләме бик зур, шартлары гаять киеренке булса да, табигый газ килеп җиткән авыллар саны арта тора. Әле шушы арада гына дәүләт кабул итү комиссиясе Якушкино авылының газүткәргеч системасын файдалана башларга, ягъни урамнардагы 6 километран артык газүткәргечне үзәк газүткәргеч системасына тоташтырырга һәм 120 фатир һәм йортка газ бирергә мөмкин икәнлеген раслады. Район җитәкчелегенең җитди кайгыртуы нәтиҗәсендә газлаштыру эше тизләтелгән Фома авылында әлегә челтәр газы кереп бетмәгән йортлар да табигый газга тоташтырылырга әзер инде. Тагын берничә авылда шулай ук дәүләт комиссиясенең соңгы сүзен әйтүен генә көтәләр.





## Хөрмәтле шәһәрлеләр!

***Район хакимияте быел сезгә хәерле Яңа еллар теле һәм түбәндәге бәйрәм программасын тәкъдим итә:***

Узган елдагыча,быел да микрорайоннарда иң ямьле Яңа ел чыршысына, иң матур бизәлгән административ биналарга конкурс игълан ителә.Үзәк мәйдандагы чыршы тирәсен бизәүдә иң актив катнашучы һәм бәйрәмгә үзенең иң матур Кар кызы һәм иң тапкыр Кыш бабайларын юллаучы коллективлар да махсус призга лаек булачаклар.

Ә Чыршы бәйрәмен 26 декабрьдә 14 сәгатьтә район мәдәният йортында инвалид,мохтаҗ һәм ятим балалар өчен оештырылачак хәйрия бәйрәме ачып җибәрә.

27 декабрь көнне заявкалар нигезендә профсоюз елкалары үтәчәк.

29 декабрьдә 17 сәгатьтә район мәдәният йортына шәһәр мәктәпләренең иң актив,иң булдыклы өлкән класс укучылары Чыршы бәйрәменә җыелачаклар.

Үзәк Чыршыны ачу 28 декабрь көнне 14 сәгатьтә планлаштырыла.Мәйданда Кыш бабай һәм Кар кызын каршы алу,оешма-предприятиеләрдән килгән Кыш бабай һәм Кар кызларының чыгышын карап бәяләү,әкият персонажлары балы,алдан игълан ителгән конкурсларга йомгак ясау каралган.Шунда ул яшьләр өчен дискобал төрле күңел ачулар,шашлык,коймаклар әзерләнәчәк,сәүдә нокталары эшләячәк.

31 декабрь көнне Үзәк чыршы янә норлатлыларны үз янына чакыра.18 сәгатьтә урманнан Кыш бабай һәм Кар кызын каршы алу,массакүләм күңел ачулар башлана.20 сәгатьтән район мәдәният йортында бал-маскарад була.

6 гыйнварда мәдәният йортында «Раштуа очрашулары»на рәхим итегез!

13 гыйнварда-искечә Яңа ел көнне Кыш бабай һәм Кар кызы янә халыкны сәламларга киләчәк,дискобал,күңел ачулар дәвам итәчәк.Ә мәдәният йортында бу көнне ветераннар «Зәңгәр ут» кичәсенә җыелачаклар.

**Яңа елда сезгә бәйрәм кәефе булдыру,күңелле ял бүләк итү өчен район мәдәният йортында махсус әзерлекле группалар эшләячәк.Сез якыннарыгызны,туганнарыгызны Яңа ел белән өйдә котларга теләсәгез биредәге хезмәт күрсәтү бюросына мөрәҗәгать итә аласыз.Шәһәр оешма-предприятиеләре үз хезмәткәрләре балалары өчен культура йортында «Тылсымлы сандык» тамашасына заявка бирә ала.**

***Яңа елның кабатланмас,сихри мизгелләрен озаграк хәтерегездә саклыйсыгыз килсә,сез һәр тамашада катнашырга тырышырсыз дип уйлыйбыз.***

***Яңа ел белән сезне!***

## Машина төзү заводы яңалыклары

### Заказчылар-Төмән,Сургуттан

«Машина төзү заводы» акционерлык җәмгыятендә җитештерелә торган чистарту корылмаларына заказ бер дә бетеп тормый.Әле күптән түгел генә «Тюменнефть» нефть чыгару идарәсе заказы буенча эшләнгән КУТМ-120, КУТМ-60, КУ-12 маркалы су чистарту корылмалары озатылды аларга.Берничә ел элек үзләштерелгән корылма-ВТК-89 маркалы суны нефть продуктларыннан чистату җиһазларына заказ бирүчеләр исемлеге дә зур.Аларның бер партиясе Монголиягә кадәр озатылды хәтта.Хәзер машина төзүчеләр Казандагы «Нефтепром» фәнни- тикшеренү институты белән дә эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырдылар-заводка заказлар килеп кенә тора.

### Комплекска-реконструкция эшләренә

Җәмгыять «Норлат» агрофирмасының дуңгызчылык комплексындагы технологик линияләрне реконструкцияләүдә дә ярдәм кулын сузарга булды.Өлкән мастер Сергей Васильевич Филиппов җитәкчелегендәге төзүчеләр эшләячәкләр Иске Чаллыда.

### Яңа продукция-терлекчелек өчен

Якын киләчәктә машина төзүчеләр терлекчелек объектлары өчен җиһазлар да җитештерә башлаячаклар төсле тоела.Ни өчен дигәндә,»Норлат» агрофирмасы заказы буенча әлегәчә үрнәк өчен дип эшләнгән өч данә автоэчергечләр өчен ясалган су җылыткычны икенче як кулай дип тапкан.Агрегатны үз күзләре белән күреп киткән Чирмешән районы хуҗалыклары да бу яңа төр җиһазга заказ биргәннәр.һәм,бусы соңгысы да булмастыр,мөгаен.

### 63 йорт

Бүгенге көнгә тимер юлчылар поселогындагы Горький, Лермонтов, Кутузов урамнарында шул кадәр йортны машина төзү заводы газ җибәрүгә хәзерләде.Бу эшне нигездә Хәниф Әхмәтвәлиев,М.Сафиуллин,Александр Германов,Леонид Лачугин кебек үз эшенең осталары булган эретеп ябыштыручылар башкарды.Гомумән,әлеге егетләр соңгы елларда газүткәргечләр эретеп ябыштыру кебек четереклe,шул ук вакытта җаваплы булган бу эш буенча специальләштеләр.Аларның әледән-әле Лениногорск шәһәрендәге укыту комбинатында укып белемнәрен ныгытулары газүткәргеч торбалар эретеп ябыштыруга хокук бирүче таныклыклар алып кайтулары да шул хакта сөйли.

Бүген әлеге осталар поселокның Пионерская,Комсомольская,40лет Победы,Фрунзе,Киров урамнарындагы йортларны газлаштыру белән мәшгульләр.

### Бу данлыклы Норлат культиваторлары

Машина төзү заводы данын бөтен җөмһүриятебезгә яңгыраткан Норлат культиваторларына ихтыяҗ һаман үсә.Кыска вакыт эчендә 42 культиватор җитештергән завод ел азагында тагын 75 шушындый агрегат ясауга эшләнмәләр әзерләп куйды.Язга таба аларны тулысынча комплектлап куярга да ниятлиләр заводта.Элеккегечә бу эш белән Валерий Феоктистов һәм Николай Кочетковның слесарьлар,Юрий Кудряшов һәм Анатолий Анохин җитәкчелегендәге эретеп ябыштыручылар бригадалары шөгыльләнә.Токарьлар Владислав Суровцев,Ильяс Собханкулов,Нурислам Әюпов та алар белән килешеп эшлиләр.Тулаем бу процесска заводның техник бүлеге бик оста җитәкчелек итә.

Шуны да әйтергә кирәк,күптән түгел Норлат машина төзүчеләре үрнәгендә КБМ-10 культиваторлары җитештерә башлаган Чистайдагы махсус автоҗиһазлар заводының агрегатлар өчен катлаулы узел йомшарткычлар ясап бирүләрен сорап нәкъ менә норлатлыларга мөрәҗәгать итүләре дә машина төзүчеләрнең данын тагын да күтәрде.

## «Безнең принцип бер: кешеләргә хезмәт итү»

# Иң төп документыбыз шушы

**Тимер ишекләр артында**



65 елда паспорт хезмәте озын да, бай эчтәлекле дә юл үтте. Бу вакыт эчендә ул служба төрле үзгәрешләр дә кичерде, берничә мәртәбә исемен дә алмаштырды..., әмма һәрвакытта да бер принципка - кешеләргә хезмәт итү максатына тугрылыклы булып калды. Район эчке эшләр бүлегенең паспорт - виза хезмәте бүлеге башлыгы милиция майоры Минталип Харис улы Гыйрфанов әңгәмәбезнең башында ук әйтте моны. Кыланмаган да, арттырмаган да икән. Кабул итү көне булмаса да, әңгәмәбез буена бүлмә ишегенең ябылып торганы булмады диярлек, телефон да сәгать ярымга унбиш кенә тапкыр чылтырагандыр. Керүчеләрнең я бланк тутырып, я фоторәсемнәр китерүләре, я югалткан паспортлары урынына яңаны алу тәртибе белән кызыксынып, я районга кайтып урнашуларын теркәтергә дип, яки башка берәр сорау белән килүләре иде. Кыскасы, шунда утырган арада гына да паспорт службасының нинди вазифалар башкаруы турында анда эшләүчеләрнең үзләреннән сөйләтмичә дә белеп чыгарга мөмкин иде. Ә монда башлыктан кала тагын өч кеше - баш инспектор Венера Владимировна Ефремова, инспектор Рифкать Таһир улы Гобәйдуллин белән баш инспектор Нина Петровна Сибулатова эшлиләр. Беренчеләренең мондагы эш стажлары 4 - 5 ел булса, соңгысыныкы ике дистә елдан артып китә инде. Хезмәт вазифалары һәркайсыныкы анык билгеләнгән булса да, монда бер - береңне алмаштыру прицибы хакимлек итә: кеше йомыш белән килгән икән, хезмәттәшең үз урынында булмаса да, килүчене борып чыгармаска, кирәкле консультацияне биреп, хәлеңнән килә икән - аның йомышын йомышлап озатырга кирәк. Ә монда эш күпкырлы. Бүлектә паспортлар тутырып бирәләр, билгеле бер яше тулганнарыкына фоторәсем ябыштыралар, паспортларга эчке битләр тутыралар, район территориясендә яшәүче һәм читтән кайтып урнашкан гражданнарны теркәп баралар ( прописка дигән нәрсә күптән юк бит инде), учеттан төшерәләр, алимент түләүчеләрне, дәүләткә бурычы булганнарны, туганнары аның белән элемтәне югалткан кешеләрне эзләтәләр, күпсанлы соратулы язуларга җавап бирәләр һәм үзләре дә шундый соратулар җибәрәләр, гражданнарны кабул итәләр, төрледән - төрле эчтәлектәге гаризаларны карыйлар, штрафлар түләтәләр... Ел туса Законга нинди дә булса өстәмә яки төзәтмә кертә тора тагын. 1992 елның 6 февралендә гражданлык турында Закон кабул ителгәннән һәм ТР Президентының республикабызга килүче гражданнарны теркәү турында Указы чыкканнан соң гына да күпме мәшәкать артты. Хәзер менә паспорт реформасы алда тора.

### ...плюс паспортлаштыру

Яңа гомумдәүләт паспорт реформасы турындагы мәсьәлә инде моннан унбиш еллап элек кузгатылган иде, әмма «...төп документ турында»гы Указга Б.Н.Ельцин былтыр гына кул куйды әле. Бераз соңрак, 8 июльдә «Россия Федерациясе гражданының паспорты, РФ гражданы паспортының бланкы үрнәге һәм тасвирламасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» РФ Хөкүмәте карары дөнья күрде. Нәкъ шул ике документ күптән түгел ТР Парламентында каты бәхәс кузгатты да инде.

Татарстанда Россиянең яңа паспортларын бирү мәсьәләсе ахырынача хәл ителмәгән әле, әмма районга яңа «кенәгәләр» кайту белән паспорт - виза хезмәтенең мәшәкатьләре дүрт - биш тапкыр артачагы көн кебек ачык. Хәзер бит паспортлар элеккечә 16 яшьтән түгел, 14 яшьтән бирeләчәк, ә паспортларны алыштыру 2006 елның 31 декабренә кадәр сузылачак ди. Яңа паспорт бушлай бирелмәячәк. Дөрес, кайбер категория гражданнарга бу мәсьәләдә ташламалар ясау каралган дигән сүз йөри, әмма бу хакта хөкүмәт карары юк әле.

Районда паспорт алыштыру эшенә әзерлек дәрәҗәсе нинди, дигән сорауга М.Х.Гыйрфанов эш күп әле диде. Бүлек хезмәткәрләре махсус курс та үтәргә тиешләр, өстәмә штат берәмлекләре дә кирәк булачак. Хәзер биредә халыкны яшь төркемнәре буенча якынча исәпләү бара, паспорт алыштыруның графигы чамалана.

### Анастасия Петровна һәм Нина Петровна

Анастасия Петровна Белованы искә алып үтмәсәк, (авыр туфрагы җиңел булсын), аның белән бергә эшләгән кешеләр безне гафу итмәсләрдер. Район эчке эшләр бүлегенә 1963 елда ОБХССның оперуполномоченные булып эшкә килә ул, ә бер елдан аңа паспорт өстәле белән җитәкчелек итүне ышанып тапшыралар. Һәм ялгышмыйлар. Энергияле, көчле рухлы; форма киеме гәүдәсенә бик килешеп торган ул хатын - кыз ул эштә кирәкле барлык сыйфатларга ия була. Чиктән тыш таләпчән дә, пөхтә һәм насмуслы да була ул. Характерында ир - атка хас сыйфатлар күбрәк тә булгандыр әле аның. Аңардан курка да, шул ук вакытта үзен бик нык хөрмәт тә итә торганнар иде. Совет хезмәткәрләре семинарларында аңа сүз бирелсә, райбашкарма комитетының утырышлар залында аерым бер тынлык урнаша торган иде... Һәм аның бу сыйфаты һич тә ясалмалылык түгел, ә фәкать бу хатын - кызның үз өстенә нинди авыр йөк алганлыгын һәм ул эшнең никадәр җаваплы булуын аңлавыннан иде.

Кормыш авыл Советы секретаре Нина Петровна Сибулатованы да бик озаклап күзли һәм таләпчәнлек белән өйрәнә ул. Аңарда да үзенә хас сыйфатларны күрә - вазифаларын җитдилек һәм игътибар белән башкара, кулы эшкә ятып тора. Паспорт өстәленә документларны нәкъ вакытында һәм бер хатасыз - төзәтүсез китерә. «Безгә эшкә кеше кирәксә, син - беренче кандидат» ди аңар Анастасия Петровна. Һәм 1975 елның 20 августында Нина Петровна Сибулатованың биографиясендә яңа сәхифә ачыла. Эшнең нәкъ кызган чагына туры килә ул - 1976 елның 1 гыйнвареннан авыл халкын тулысы белән документлаштыру башлана. Вакытлыча эшкә кабул ителгән булышчылар булса да, ялсыз - нисез эшләргә туры килә. Башта Нина Петровна авылларга фотограф белән бергә чыгып китә, аннан инде шул ук маршрутлар буйлап әзер паспортлар белән. Яңгырга - буранга, юлсызлыкка һәм ераклыкка карап тору булмый ул чакта. Алты ел буена әнә шулай киеренке шартларда эшлиләр алар. Нина Петровна Сибулатова паспорт - виза службасында хәзер адрес - белешмә эшен алып бара. Игътибарлылык, пөхтәлек, катгыйлыкны бер эштә дә артык түгел дип саный ул. Үз эшен бик яратып башкара ул һәм шушында инде күптән түгел генә үзенең гомер юбилеен да билгеләп үтте.





Инде менә һөнәри юбилейлары да килеп җитте һәм монысы - паспорт службасының хөрмәтле хезмәткәрләренең барысын да бергә уртак бәйрәме белән котлар өчен үзе бер форсат. Берочтан Яңа ел белән дә!

**Т.НАЗАРОВА.**

**Рәсемнәрдә: М.Х.Гыйрфанов, Н.П.Сибулатова, В.В.Ефремова, Р.Т.Гобәйдуллин.**

**Н. АЗИЗОВ фотолары.**

## Уразалар мөбәрәк булсын!

## Ураза аена милади һәм һиҗри көннәр җәдвәле

| Милади көннәр 1997-1998 еллар | Атна көннәре | Һиҗри көннәр 1418 ел | Кояш чыга | Кояш бата | Көн озынлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| **1997 ел декабрь (Рамазан) аена** | | | | | |
| 31 | чәршәмбе | 1 | 8.13 | 15.20 | 7.06 |
| **1998 ел гыйнвар (Рамазан)аена** | | | | | |
| 1 | пәнҗешәмбе | 2 | 8.13 | 15.21 | 7.08 |
| 2 | җомга | 3 | 8.13 | 15.22 | 7.09 |
| 3 | шимбә | 4 | 8.13 | 15.23 | 7.11 |
| 4 | якшәмбе | 5 | 8.12 | 15.25 | 7.13 |
| 5 | дүшәмбе | 6 | 8.12 | 15.26 | 7.14 |
| 6 | сишәмбе | 7 | 8.11 | 15.28 | 7.16 |
| 7 | чәршәмбе | 8 | 8.11 | 15.29 | 7.18 |
| 8 | пәнҗешәмбе | 9 | 8.10 | 15.31 | 7.21 |
| 9 | җомга | 10 | 8.09 | 15.32 | 7.23 |
| 10 | шимбә | 11 | 8.09 | 15.34 | 7.25 |
| 11 | якшәмбе | 12 | 8.08 | 15.36 | 7.28 |
| 12 | дүшәмбе | 13 | 8.07 | 15.37 | 7.30 |
| 13 | сишәмбе | 14 | 8.06 | 15.39 | 7.33 |
| 14 | чәршәмбе | 15 | 8.05 | 15.41 | 7.36 |
| 15 | пәнҗешәмбе | 16 | 8.04 | 15.43 | 7.39 |
| 16 | җомга | 17 | 8.03 | 15.44 | 7.42 |
| 17 | шимбә | 18 | 8.02 | 15.46 | 7.45 |
| 18 | якшәмбе | 19 | 8.00 | 15.48 | 7.48 |
| 19 | дүшәмбе | 20 | 7.59 | 15.50 | 7.51 |
| 20 | сишәмбе | 21 | 7.58 | 15.52 | 7.54 |
| 21 | чәршәмбе | 22 | 7.56 | 15.54 | 7.57 |
| 22 | пәнҗешәмбе | 23 | 7.55 | 15.56 | 8.01 |
| 23 | җомга | 24 | 7.54 | 15.58 | 8.04 |
| 24 | шимбә | 25 | 7.52 | 16.00 | 8.08 |
| 25 | якшәмбе | 26 | 7.51 | 16.02 | 8.11 |
| 26 | дүшәмбе | 27 | 7.49 | 16.04 | 8.15 |
| 27 | сишәмбе | 28 | 7.47 | 16.06 | 8.19 |
| 28 | чәршәмбе | 29 | 7.46 | 16.08 | 8.22 |
| 29 | пәнҗешәмбе | 30 | 7.44 | 16.10 | 8.26 |

**30 - 31 гыйнвар, 1 февраль (1 - 3 шәүвәл) - Ураза бәйрәме. («Юлдаш» тан).**

# ШИКӘРНЕҢ ТАТЛЫСЫ ТИР ТАМЫЗЫП АЛЫНА

**Районның дәүләткә шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәсен уңышлы үтәве турында хәбәр иткән идек инде. Әле аннан соң да Норлат шикәр заводының кагат кырына машиналар килә торды. Бүген инде гомуми уңышка кемнең нинди өлеш кертканлеге, шул ук вакытта кемнең ни өчен йөкләмәсен тутыра алмаганлыгы турында да тәфсилләп сөйләргә мөмкин. Район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең шикәр чөгендере буенча баш агрономы Ф.Мингалимов белән әңгәмәбез шул хакта.**

**- Фоат Хаварисович! Быел чөгендер хәзерләүнең гаять киеренке шартларда тәмамланганлыгы хәтердә әле. Ул чорда көннәр тагын бераз гына уңай торса, нәтиҗәләр яхшырак булган булыр иде...**

- Хакыйкатьтән беркая да кача алмыйсың. Хәзерләнгән 115 мең тоннадан артыграк чөгендер чималының 62 мең тоннага якыны, ягъни яртысыннан артыгы чөгендер сату заданиесен үтәүгә ирешкән ун хуҗалык өлешенә туры килә.

**- Шулай булгач, район планын үтәүгә аеруча зур өлеш керткән ул хуҗалыкларны тагын бер тапкыр искә төшерү дә артык булмастыр.**

- Иң күп чөгендерне «Киекле» хуҗалыгы тапшырды - 16 мең тоннадан артык чимал озатып, килешү йөкләмәсен 154 процентка үтәде. Хуҗалык шикәр чөгендере игелгән 565 гектарның ( бу - районда иң зур мәйдан) һәркайсыннан уртача 288 әр центнер татлы тамыр тапшырды дигән сүз бу. Заводның ярдәмче хуҗалыгында ул күрсәткеч тагын да югарырак булды. «Кондырча»лылар гектардан 282 шәр центнер, барлыгы 10 мең тонна чамасы чимал озаттылар. Тапшырылган чөгендерләре 12 мең тоннага якын булган хафизовлылар заводка бер гектардан 228 әр центнер чөгендер китерделәр. «Родина», «Рассвет», «1 нче Май», Синдряков исемендәге,«Тәрнәс» хуҗалыклары игенчеләре дә район йөкләмәсен тутыруга саллы гына өлеш керттеләр, «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы да дәүләт алдында бурычлы булып калмады. Аларда гектардан 200 центнер тирәсе һәм аннан да күбрәк чимал тапшыруга ирештеләр.

**- Элегрәк иң әүвәл чөгендернең гектарыннан алынган уңыш турында сүз алып барыла иде, ә бүген заводка тапшырылганы төп күрсәткеч итеп куела.**

- Чит иллләрдә, шул исәптән без хезмәттәшлек итәторган Франциядә чөгендернең уңышын күптән инде бер генә күрсәткеч - гектардан күпме шикәр чыгышы белән исәплиләр. Хәзер бездә дә эш шуңа бара. Әмма быел бер гектардан тапшырылган чөгендер турында сүз алып баруыбыз иң элек басудан төяп китерелгән һәм заводка кабул ителгән чөгендернең үлчәүләре арасында аерма шактый булуыннан. Әйтик, быел заводка китерелгән чимал 141 мең тонна чамасы булса, аның исәпкә алынганы 115 мең тоннадан аз гына күбрәк. Йөкләрнең 25,7 мең тоннадан артыгы чөгендернең пычраклылыгы, чүплелеге өчен һәм башка сәбәпләр буенча чигерелгән дигән сүз бу.

**- Бик күп бит бу?**

- Район буенча 18,3 процент. Дөрес, барлык хуҗалыкларда да бердәй түгел бу күрсәткеч. Әйтик, килешү йөкләмәсен 137 процентка үтәгән «Рассвет»та чөгендернең пычраклылыгы 10,3 процент кына булды, ягъни 459 тоннасы гына чигерелде. Ә менә МСО ярдәмче хуҗалыгыннан килгән барлык чөгендер фәкать 512 тонна булды, аның да 156 тоннасы, ягъни өчтән бере диярлек исәпкә кермәде. Шулай итеп, «Рассвет» бер гектардан уртача 221 центнер чөгендер тапшырса, «Строитель»дә бу күрсәткеч ...35 центнер гына булды.

**- Аерма җиде тапкыр диярлек дигән сүз түгелме соң бу?**

- Шулай шул. Һәм моңа әллә ни гаҗәпләнәсе дә юк - кем җиде кат тирен агызып эшләгән, аның хезмәтенең нәтиҗәсе дә бар, ә кем әйдәярарга гына йөргән, аның ярты - йорты хезмәте дә җилгә очкан. Югыйсә бит районда шикәр чөгендерен үстерүдә үрнәк алырлык уңай тәҗрибәләр бик күп, район җитәкчелеге дә чөгендер игү технологиясен камилләштерә, бу эштә кул хезмәтен киметә барыр өчен зур мөмкинлекләр тудыра. Татлы тамыр игүгә җитди караган хуҗалыкларда ул мөмкинлекләрдән нәтиҗәле файдаланалар. Әйтик, шул ук «Киекле», «Кондырча», «Рассвет», Хафизов исемендәге хуҗалыкларда, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында шикәр чөгендере чәчеләсе мәйданнар көздән яхшылап эшкәртелеп, тиеш булганда известьлап, кирәк кадәр микъдарда минераль ашлама кертеп калдырылды. Монда ул хуҗалыкларның агрономнары белән берләттән шикәр чөгендере игү буенча звено башлыкларының да үзләре белеп эшләүләре зур роль уйный. «Кондырча»дан Шамил ага Яруллин турында бу җәһәттән нинди генә мактау сүзләре әйтсәң дә артык булмас. Шул ук хуҗалыктан Әсгать Тәмаев һәм Әнвәр Вәлиев, «Киекле»дән Азат Әхмәтвәлиев һәм Рәдиф Кәримов, «Рассвет»тан Касыйм Саттаров, Хафизов исемендәге хуҗалыктан Михаил Ивашкин, Николай Ильдухин кебекләр күбрәк булсамы?

Югары уңышның алшартлары турында сөйләгәндә чөгендер игүгә җитди эш итеп караучы хуҗалыкларда бу культураны яхшы элгәрләрдән бушаган мәйданнарга урнаштыруга зур әһәмият бирелүен дә әйтергә кирәк. Быел районда бу культура нигездә уҗым культураларыннан бушаган кырларга, шул исәптән мең ярым гектардан артыгы чиста парда игелгән уҗым культураларыннан соң чәчелде. Ә менә кайбер хуҗалыкларда, шул исәптән нефтебаза, МСО ярдәмче хуҗалыкларында чөгендерне былтыр сабан культуралары игелгән мәйданнарга чәчтеләр. Хәер, ул ике хуҗалыкта шикәр чөгендере игүнең тәртипкә салынган чәчү әйләнеше дә булмаганда анысы гаҗәп тә түгел.

Ә элгәрнең ниндилеге беренче чиратта туфракның туклыклы матдәләргә ихтыяҗы, кырның чүплелеге күзлегеннән чыгып караганда мөһим. Ул яктан «Рассвет»та чөгендернең һәр гектары тәэсир итүчән матдәдә 764, «Киекле»дә 614, «Кондырча»да 546, ә шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында...1027 килограмм минераль сый алды,аның да зур өлеше көздән кертеп калдырылды. Ә менә нефтебаза, МСО ярдәмче хуҗалыкларында ул күрсәткечләр 139 һәм 194 килограмм гына булды, «Заветы Ильича», Мичурин исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда да 200 килограммнан артыграк кына тәшкил итте.

Уңыш факторлары арасында чәчү сроклары да бик мөһим. Быел районда бу эш май буена сузылды. Уңай яктан телгә алынган хуҗалыкларда бу мәсьәләдә дә зур оешканлык күрсәттеләр, кайсыларының механизаторлары әле башка хуҗалыкларга да ярдәмгә бардылар. Ә инде чәчү соңга калган икән, чөгендернең тигез тишелмәвен яки бөтенләй чыкмавын көт тә тор. Бу исә басуны чүп басачак дигән сүз.

**- Анысына каршы гербицидлар җитәрлек бит инде хәзер...**

- Гербицидлар куллануның да рәте бар шул. Чәчү срокларының сузылуы кайбер чүп үләннәренең инде аларны гербицидлар белән генә җинеп булмаслык дәрәҗәдә күтәрелүенә китерә. Икенче яктан, иң кирәкле гербицидның нәкъ вакытында яки җитәрлек кадәр булмавы да бар.

**- Уңыш җәй буе формалашса да, аны вакытында һәм югалтуларсыз җыеп алуның да әһәмияте кечкенә түгел бит...**

- Ничек кенә әле һәм быел анысы аеруча ачык күренде. Дөрес, әле урак та төгәлләнмәгән булуга карамастан, күпчелек хуҗалыкларда бу эшкә оешкан төстә керештеләр. Шуңа күрә аларда чөгендер казу чагыштырмача иртә төгәлләнде. Ә менә кайбер хуҗалыкларда чөгендер казу комбайннарын ремонтлауны бик соңга калдырдылар. Шуңа күрә «Әлмәт», «Үрнәк», «Таң» һәм кайбер башка хуҗалыкларда икенче урак бик соңга калып башланды. Ә МСО, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында, «40 лет Победы»да күпчелек чөгендерне башкалардан арендага алынган яки ярдәмгә килгән техника казыды. Чөгендер казу иң соңга калган Мичурин исемендәге хуҗалыкка да быелгы көз яхшы сабак булырдыр. Хәер, сабак дигәннән, быелгы икенче урак башка күп кенә хуҗалыкларга да сабак бирер дип ышанасы килә. Әйтик, «Әлмәт» хуҗалыгының килешү йөкләмәсен нибары 73 тоннага, «40 лет Победы» 54, «Таң» һәм «Чирмешән»нең 119 - 120 тоннага гына тутыра алмый калулары уйланырлык. Уңышның бөртегенәчә җыелып бетмәве дә бу, заводка озатканда чистартып бетермичә пычраклыгы аркасында югалту да. Ә тегесе дә, монысы да иң элек эшне оештырып җиткермәү һәм соңга калу нәтиҗәсе.

**- Нәкъ менә шуңа күрә дә район җитәкчелеге быел чөгендер казу техникасын ремонтлауны игътибар үзәгенә алу, аерым алганда, «Сельхозтехника» берләшмәсендә шушы максаттан махсус звено оештыру бурычын алга куйды да бит инде.**

- Хуҗалыкларда да моның мөһимлеген яхшы аңласалар, татлы тамырдан мул уңыш алуның барлык факторларын да күздә тотып эш итсәләр киләсе елда чөгендерчеләребезнең хезмәт нәтиҗәсе тагын да саллырак булыр дип ышанырга мөмкин. Өстәвенә, бездә бу эшнең француз технологиясен куллану буенча да шактый тәҗрибә бар инде һәм аның нәтиҗәләре ярыйсы ук яхшы булды. Француз технологиясе буенча игелгән мәйданнарның гектарыннан алынган уртача уңыш исәпләү авырлыгында гадәти технология буенча игелгәннекенә караганда 65 центнерга күбрәк тәшкил итте. Шул исәптән шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында һәм «Киекле»дә француз технологиясе гектардан 300 центнердан күбрәк уңыш бирде, башка хуҗалыкларда да аерма - шушы технология файдасына. Әлбәттә, эш технологиядә генә түгел монда, ә аның буенча эшләүчеләрнең җаваплылык тоеп, бар таләпне җиренә җиткереп башкаруларында. Димәк, нинди генә технология буенча эшләсәк тә, чөгендер кебек нәзберек культурадан мул уңыш алу барыбер иң элек үзебездән тора.

**- Алда әйткәнебезчә, шикәр төмен татыр өчен барыбер җиде кат тир тамызмыйча булмый шул инде.**

**Әңгәмәдәш**
**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

**Хатлар**

## Рәхмәтемне җиткерәм

Мин Казан шәһәренә балаларым, оныкларым янына хәл белергә барган идем. Ләкин кышның зәмһәрир салкын көннәрендә Норлатка кайта алмыйча җәфа чигүләремне сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Поезд юк, автобус йөрми, бәлки әле самолет булыр дигән уй белән аэропортта озак торырга туры килде. Дүртенче көнне бер миһербанлы кеше килеп күңелебезгә җан өрде, Норлатка кайтучы өч кешене вертолет белән алып китте.Аның Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин икәнлеген кайтып җиткәндә генә белдек.Өемә кадәр җиңел машина белән китереп куйдылар.Мин, мондый ихтирамны,хөрмәтне гомердә дә күрмәгән гади бер авыл кешесе өчен бу искиткеч зур бәхет иде.Бик сөендем..

Эшләрендә зур уңышларга ирешсен,олыгайган көннәрендә дә үзен безне хөрмәтләгән кебек олыласыннар,рәхәт яшәсен,кайгы-хәсрәт күрмәсен,дип теләкләр телим мин Ф.Сибагатуллинга.

**А.МУСИНА.**
**Югары Норлат авылы.**

## Эше күпкырлы аның

Авыл җиренә тамырлары белән бреккән, бар җанын - тәнен биреп эшләгән кешеләр турында сөйләгәндә, ничә дистә еллар инде колхозның иң җаваплы урынында хезмәт куючы, хуҗалыкның склад мөдире Мөнип ага Дәүләтшин исемен мисалга китерү бер дә гөнаһ булмас. Гомере буе авылда эшли ул. Гаделлеге, төгәллеге һәм инде хезмәтен намуслы башкаруы өчен шушы җаваплы постка куйдылар да аны. Чәчләре чаларып, маңгайлары сырланса да, күңеле көр булган кешенең йөрәге дә картаймыйдыр инде. Мөнип ага шундыйлардан. Күңелендә кешеләргә бары тик яхшылык, изгелек эшләү, аның йөзендә исә һәрвакыт елмаю, эшенә үтә дә җаваплы караштa. Шулай булмаса, бер үк постта чирек гасырдан артык гомер эшли алыр идемени?! Иртәдән кичкә кадәр бирeдән кеше өзелми. Терлекчеләр иртәнге сәгатьтән фураж алырга киләләр. Кемнеңдер шикәр комы алмаган, кемгәдер ит - бал үлчәп бирергә, ә кемгәдер эш киеме яздырып бирергә кирәк. Әйе күпкырлы хезмәт бу.

**З.ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**«Татарстан» КХАсы.**

# «Ивушка» да җылы булырмы?

**«Бүлмәләр салкын булу сәбәпле «Ивушка» балалар бакчасы 16 декабрьдән 22 нә хәтле балалар кабул итми».** СМП микрорайонының (халык теленә электән шулай кереп калган ул) төрле урынnarында шушындый игъланнар күрергә мөмкин иде. Редакциягә килеп ирешкән әлеге хәбәр буенча без дә балалар бакчасына юл тоттык.

Педагоглар кулы белән бизәлгән уен һәм йокы, кабул итү бүлмәләре тынлык һәм тәнне, җанны өшетерлек салкынлык белән каршылады безне. Коридордагы термометр уклары +4 -5 градус тирәсендә тирбәлә иде. «Җан саклаучы җылылык батареялары, шулар янына «елышкан» чәчәк атыйммы-атмыйммы дип утырган декабрист гөлләре, салкынлыктан кубып төшкән өр - яңа обойлар, һәм...озакламый биредә Яңа ел тантанасы булачагын искәртеп торучы кәгазь кар бөртекләре; төсле мишуралар...

1989 нчы елда искесе, янганы урынына ашыгыч рәвештә салынган балалар бакчасы элек-электән дә җылылыкка тиенмәгән, учреждениенең җылылык системасына берничә тапкыр капиталь ремонт та шул максатта үткәрелгән. Бакча Норлат промысел - геофизик эшләр идарәсеннән (НУГР) РОНО карамагына тапшырылгач (1992 ел) та система ике тапкыр үзгәртелеп корыла. Педагогия коллективы инде быел ниһаять җылылыкка тиенербез дип керәләр кышка. Октябрь-ноябрь айларында балалар рәхәтләнеп йөриләр бакчага. Беренче салкыннар җитүгә «Ивушка»да температура кискен төшә. Бүлмәләргә регистрлар кую, йокы бүлмәләренең тәрәзәләренә одеяллар кору, балаларны кат-кат киендереп йоклату гына да җылы саклар мөмкинлек калдырмагач, биредә тәрбияләнүче 103 баланы вакытсыз «каникулларга» җибәрергә мәҗбүр булалар. Шул исәптән беренче класста укучы 25 бала өчен болай да озын булмаган икенче уку чиреге тагын да кыскара. Тулаем коллектив исә махсус график нигезендә бинада дежур тора башлый: батареялар салкынайган очракта су агызырга әзерләнеп торалар алар.

Бакча балалар кабул итүне башларга ниятли. Шушы көннән батареялар ничек җылыныр икән соң? Шул сорауга җавап табу максатыннан без бакчаны җылылык белән тәэмин итүче НУГР котельнясында булдык.

-Гаеп бездә,-дип каршыладылар безне анда, -ике казанның берсе генә эшли, икенчесе нәкъ менә салкыннар җиткәч сафтан чыкты.

Казанның сафтан чыкканы үзе икенче сезон гына эшли икән. Былтыр геофизикларның төп базасыннан бирегә күчергәннәр аны. Оператор Вәлияр Бикинеев әйтүенчә, аны төзәтү дә әллә ни күп вакыт таләп итми. Әмма НУГР җитәкчелеге ашыкмый: мөһимрәк эшләре бардыр, күрәсең. Югыйсә, балалар бакчасы, ата-аналарның гозерләренә шулай битараф була алырлар идемени?

Әмма идарә начальнигының үз туксаны туксан.

-Декабрьнең 17сендә безгә казан ватылу турында сигнал керде, икенче көнне без аны төзәттек, ә 18е көнне балалар бакчасында шәхсән үзем булдым-батареяларга тотына торган түгел «пешерә» иде,-ди ул. Ә безнең «Ивушка» да җомга көнне булуыбызны әйтсәк, начальникның сүзенең ни дәрәҗәдә «дөрес»леккә туры килүен чамаларга була.

Бакча алдан билгеләнгәнчә, 22 нче декабрь көнне балалар кабул иткән. Бүлмәләрнең ни дәрәҗәдә җылынуын белешү максатында без телефон аркылы бакча мөдире Г.Әбделмәнова белән элемтәгә кердек.

-Аскы катта +15, икенчедә 18 градуска җитә температура,-диде безгә Гөлсинур Гомәровна сөенеп.

Килешегез, батареялар начальник раславынча кулны «пешерми». Әмма, факт факт булып кала: казан төзәтелгән. Әмма...

Бусы бер нәрсә. Котельня эшчеләре әле казанның төзәтелеп тә, киләчәктә ышанычлы эшләвен гарантияләмиләр. Ни өчен дигәндә, биредә суны йомшарту һәм чистарту өчен махсус җиһаз булмау сәбәпле юшкын утырып, торбаларны еш сафтан чыгара. Аннары, халыкның һичнинди кисәтүләргә дә карамастан, ягулык торбаларындагы судан файдаланулары да җылылык кулланучылар файдасына түгел.

Инде балалар бакчасы турында сүз кузгатканбыз икән, быел үзара исәп-хисап исәбенә 1 нче ПМК ның әлеге объектны ремонтларга вәгъдә итеп тә «мөһим объект түгел бу» дип бармакка бармак та сукмавын әйтми калу мөмкин түгел. Ун еллап элегрәк булса, алай дия алмаслар иде шул төзүчеләр. НУГР җитәкчелеге дә ул чакта күрә-белә торып, ачы салкыннарда котельняның тулы көченә эшләвен тәэмин итми калмас иде, мөгаен. «Бөтен яхшыны-балаларга» дигән девиз көн тәртибеннән төшеп калса да, балалар балалар булып кала бит әле. Иң якты, алар иң көтеп ала торган Яңа ел бәйрәмен булса да шатлык-сөенеч белән каршыласыннар иде инде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Иске Әмзә авылында яшәүче сеңелебез һәм апабыз **Исламия Садыйк кызы Гыйләҗеваны** 60 яшь тулуы белән һәм Яңа ел белән котлыйбыз.

Гел шатланып яшә, хәсрәт күрмә,
Тыныч булсын һәрчак күңелең.
Бәрәкәтле матур тормыш сиңа,
Кояшларга тиңе гомернең.

**Абыйсы Нурислам, энесе Исламгали, сеңлесе Җәмилә, энесе Илһам гаиләләре белән.**




## САТАБЫЗ

**Т - 40 тракторы - 17 млн., УАЗ - 469 - 15 млн., ГАЗ - 52 - 12 млн. сум.**
Яр Чаллыда тел.: 51 - 12 - 50.

***

**Капиталь гараж (хәрбиләштерелгән янгын сагы каршында).** Тел.: 5 - 1 - 70.

***

**Ашыгыч рәвештә 1993 нче елгы ВАЗ 21013.** Тел. 5 - 19 - 06, 5 - 13 - 81.

***

**Әйбәтхәлдәге «Москвич ИЖ - 2715».Бәясе 11 млн сум.** Тел. 2 - 12 - 75.

***

**Әрҗәле УАЗ.** Адрес.: Кошки авылы, Молодежная ур., 17, теләсә кайсы вакытта.

***

**1997 елның июль аенда чыккан, 18 мең км. юл үткән, 6 урынлы, тентлы «Газель» автомашинасы (бәясе 46 млн. сум).** Тел.: 5 - 11 - 58.

***

**1993 нче елның декабрендә чыккан ВАЗ - 2121.**
Арадашчы тел.: 2 - 17 - 19, теләсә кайсы вакытта.

***

**Коттедж.** Адрес: Московская ур., 5 - 36.

***

**1996 нчы елгы ВАЗ - 21213 «Нива».** Тел.: 2 - 22 - 95, теләсә айсы вакытта.

***

**Ашыгыч рәвештә дизель Ауди - 81 машинасы.**
Тел.: 5 - 27 - 41.

***

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Сәүдә итү өчен вагончык сатып алам.**
Тел.: 2 - 19 - 60.

# Яңа ел чыршысы- һәркем өчен бәйрәм



Яңа 1998 нче ел якынлаша. Аңа санаулы көннәр генә калды. Нигездә аңа алдан хәзерләнәләр. Ашыгып нидер онытырга, нәрсәгәдер өлгермәскә мөмкин. Шулай итеп бәйрәмнең яме китүе дә бар.

Яңа ел бәйрәмен үткәргәндә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Шуңа да массовый чара үткәрү өчен җаваплы кеше чыршы урнаштыру өчен бинаны алдан хәзерләргәтиеш. Агач, шулай ук яна торган түбәле биналарда икенче каттан да биек булмаган урыннарда гына рөхсәт ителә Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү. Чыршыны нык нигездә урнаштырырга кирәк. Ул бинадан чыгуны кыенлаштырмасын. Чыршының ботаклары стена һәм түшәмнән 1 метрдан да якын булмаска, җылыткыч җиһазларга тимәскә тиеш. Урман кунагын целлулоид һәм тиз ут кабучан башка уенчыклар белән бизәү, янгынга каршы состав белән эшкәртелмәгән мамык урау, стеарин шәмнәр кабызу, аңа бертолет тозы сибү тыела. Чыршыга лампочкалар куюны бары тик тәҗрибәле электрчыларга тапшырырга кирәк. Иллюминациянең аз гына төзексезлеге беленгәндә дә аны сүндерү зарури.

Балалар белән массовый чаралар үткәргәндә бинада дежур укытучылар, класс җитәкчеләре һәм тәрбиячеләр дә булырга тиеш. Алар белән янгын куркынычсызлыгы турында инструктаж үткәрергә һәм янгын чыккан очракта балаларны эвакуацияләү кагыйдәләрен аңлатырга кирәк. Чыршы урнаштырылган залда 2-4 төзек янгын сүндергеч һәм йон одеал булырга тиеш.

Оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләре чыршы куюга рөхсәтне дәүләт янгын күзәтүе часте яисә җирле ирекле янгын бүлекләреннән алырга тиешләр.

Янгын бәйрәмегезнең ямен җибәрмәсен.

**Ә.ЭЮПОВ,**
**Норлат янгын частенең дәүләт янгын күзәтүе инспекциясе өлкән инспекторы, эчке служба капитаны.**

**Лениногорск шәһәрендә укыту үзәге 1998 нче елның 12 нче гыйнварыннан түбәндәге белгечлекләр буенча укулар үткәрә:**

1. **Персональ ЭВМнан кулланучы (оператор).**
2. **Коммуналь - көнкүреш объектларның газ хуҗалыгын куркынычсыз эксплуатацияләү өчен җаваплы.**
3. **Такелаж һәм йөк эләктерү җайланмалары буенча слесарь.**
4. **Автомобиль краннары машинисты.**
5. **Йөк күтәрү краннарын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча слесарь.**
6. **Газ һәм нефть продуктлары үткәргечләрен изоляцияләүче.**
7. **Кулдан эшләүче электр белән эретеп ябыштыручы.**
8. **Газ җиһазларын ремонтлау һәм эксплуатацияләү буенча слесарь.**
9. **Баллоннар тутыручы.**
10. **Пешекче - кулинар.**
11. **Чәчтараш.**

Безнең телефоннар: 2 - 34 - 45, 2 - 05 - 18, Агадуллин ур., 2.

## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көне 16 гыйнварда көндезге сәгать 12дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

# «Индезит» һәм «Стинол»- иң яхшы бүләк.

**Иң яхшы суыткыч һәм кер юу машиналарын бушлай илтеп бирү һәм гарантия. Безнең белән эш итү бик кулай. Моңа шәһәр һәм районның күп кешесе инанырга өлгерде инде. Алардан сорашыгыз. Ир - атлар, алда Яңа ел һәм Раштуа, сөекле әниләрегезгә һәм хатыннарыгызга бүләк ясагыз. Бәяләр әлегә элеккегечә.**

***27 нче декабрьдән 14 нче гыйнварга кадәр сатып алучылар, бу чорда лотерея да бар. Призга - безнең кибет товарлары. Бәлки сезгә бәхет елмаер.***

Адрес: «Техника» кибете, 2 нче кат.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Норлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. Заказ N 10346.